# Татар телен һәм әдәбиятын укытуда уен технологияләре



**Укучы мәктәптә үзе нәрсә дә булса иҗат итәргә өйрәнмәсә, ул тормышта да һәрвакыт башкаларны кабатлап кына яшәячәк.**

**Л.Н. Толстой**

**Тәнкыйди фикерләү технологиясе фәлсәфә, психология, педагогика фәннәренә нигезләнә. Анын авторлары – америка галимнәре**

**Чарльз Темпл,**

**Дженни Стил,**

**Курт Мередит,**

**Скот Уолтер.**

**Россиядә бу технология 1997 еллардан гына кулланыла башлый.**

## Тәнкыйди фикерләү технологиясе буенча үткәрелә торган дәрес гадәттә 3 этаптан тора:

1. Кызыксындыру – булган белемнәрне искә төшерү; яңа темага карата кызыксыну уяту; укучыларда максат булдыру. (Укучы үзалдына “Мин нәрсә беләм?” , “Нәрсә белергә телим?” дигән күзаллау формалаштырырга тиеш.)

2. Аңлау, мәгънәсенә төшенү – яңа мәгълүматны кабул итү, максатларны ассызыклау. (Укучы беренче өлештә куелган сорауларга җавап таба. Монда аңа укытучы, иптәшләре ярдәм итә.)


3. Рефлексия – өйрәнелгән мәгълүматны иҗади анализлау, бәяләү, яңа максатлар кую. Укучының үзе ясаган нәтиҗәләре мөһим.

**Дәреснең беренче этабында идеяләр “кәрзине”, кластер, буталган логик чылбыр, фаразлар агачы, дөрес һәм ялгыш фикерләр һ.б. кулланыла.**

**Икенче этапта ми һөҗүме, инсерт, фишбоун, туктап уку, саллы һәм гади сораулар, Блум ромашкасы, плюс – минус кызыклы, беләм – белергә телим – белдем таблицаларын тутыру һ.б. алымнар отышлы.**

**Өченче этапта исә эссе, синквейн, рафт, борт журналы, фикерләүнең алты эшләпәсе кебек алымнар кулланыла.**

**Кластер төзү алымы – булган белемнәрне системага салудан гыйбарәт. Кластер сүзе бәйләм, тәлгәш дигәнне аңлата.**



Фикерләүнең алты эшләпәсе. Бу алым рефлексия этабында кулланыла. Класс 6 төркемгә бүленә. Һәр төркем үзенең эшләпәсен киеп карый: бер проблема 6 яктан ачыклана.

**Ак эшләпә: нинди мәгълүмат белдегез? Фактлар.**

**Сары эшләпә: өйрәнгән мәгълүматның уңай яклары. Позитив фикерләр.**

**Кара эшләпә: нинди тискәре яклары күренде? Тәнкыйть күзлегеннән карау.**

**Кызыл эшләпә: сездә нинди хисләр туды? Эмоциональ кабул итү.**

**Яшел эшләпә: иҗади фикерләү, фаразлар.**

**Зәңгәр эшләпә: фикерләүне гомумиләштерү. Йомгак ясау.**

**Тәнкыйди фикер йөртү технологиясе нигезендә оештырылган дәресләрнең мөһим өлеше булып уен технологиясе тора.**

**Уен – гаҗәеп киң төшенчә. Шиллер уенны “һәр сәнгатьнең нигезе” дип санаган. Уен – мәҗбүрилектән котылу юлы, иҗат эшенең беренче адымы.**

## Уеннарны берничә төргә бүлеп йөртәләр:

- дидактик уеннар (укучыларда белем – күнекмәләр формалаштыруга һәм камилләштерүгә, танып – белү эшчәнлеген киңәйтә),
- тәрбияви уеннар,
- иҗади уеннар,
- коммуникатив уеннар.

**Үткәрү методикасы буенча да алар бик күп төргә бүленә:**

**-предметлы уеннар,**

**-сюжетлы,**

**-рольле,**

**-эшлекле һ.б.**

**Формалары ягыннан:**

**-телдән,**

**-язма,**

**-өстәл һәм хәрәкәтле уеннар була.**

Игътибарыгыз өчен рәхмәт